СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“29” апреля 2019 г. — № 1-44

“Омар авыл җирлеге Советының 2018елның 11 апрелендәге 1-33 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылҗирлеге”муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар җирлеге Советы карары турында

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Мамадыш районы прокуратурасының 2019 елның 26 февралендәге тәкъдимнәре нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Омар авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-33 санлыкарары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә(17.09.2018 ел, 2-37 нче санлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 13 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 56 пунктбелән тулыландырырга:

“ 56. Юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үзләренең милкендә биләүдә яки куллануда булган җир участокларындаСосновский балтырганынбетерү (юк итү), аннан арындыру, бетерү (юк итү) буенча мөстәкыйль рәвештәүз хисабына системалы чаралар үткәрергә тиеш, (Сосновский балтырганынбетерү (юк итү) буенча чаралар аларбөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганга кадәр үткәрелергә тиеш)”.

1.2. Кагыйдәләрнең 3 бүлегендәге 26 нчы бүлекнең 171 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

“Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үз милекләрендә булган җир кишәрлекләрендәбетерү (юк итү), буенча чаралар юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) һәм физик затларның үз акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә Сосновский балтырганыбөреленгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы

үткәрелергә тиеш."

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгына И.Г.Хәсәнҗановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / И.Г.Хәсәнҗанов /